**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ШӘҺӘР ТИБЫНДАГЫ УРЫССУ БИСТӘСЕ СОВЕТЫ**

**КАРАР**

«_16_» ___02_____2026ел Урыссу штб № _3__

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы бистәсе Советының 29.11.2021 №14 карары белән расланган "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы бистәсе" муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

"Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ санлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 31.07.2020 № 248-ФЗ Федераль законы, «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында» 26.12.2008 ел, № 294-ФЗ Федераль законы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы законы нигезендә, "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы бистәсе" муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы бистәсе Советы карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Урыссу шәһәр тибындагы бистәсе» муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы бистәсе Советының 29.11.2021 №14 карары белән расланган Нигезләмәгә түбәндәге үзгәреш кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 3.10.5.6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.10.5.6. Әгәр йөкләмәдә контроль төре һәм (яисә) мәҗбүри профилактик визитлар үткәрелергә тиешле контрольдә тотылучы затлар исемлеге күрсәтелмәгән булса, мондый йөкләмәне үтәүне оештыру максатларында «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31

июлендәге 248-ФЗ санлы Федераль законның 52.1 статьясындагы 7 өлеше нигезендә Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе урынбасары йөкләмәсе кабул ителә.

2. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында рәсми бастырып чыгару юлы белән һәм http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Рәсми Татарстан» дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының бердәм порталын урнаштыру юлы белән рәсми рәвештә халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карар рәсми игълан ителгән көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы Ютазы
муниципаль районының "Урыссу
шәһәр тибындагы бистәсе" муниципаль
берәмлеге Советы Рәисе,
Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районының
шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе
Башлыгы А.Ә. Шәфигуллин